РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.08.2017 №164-п

*Районның социаль-икътисадый үсешенә*
*зур өлеш керткән предприятиеләр турында*

Районда эшләп килүче предприятие һәм оешмаларның 2016 ел эш нәтиҗәләрен караганнан соң,

КАРАР БИРӘМ:

1. Районның социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән, җирле бюджетка 2016 елда 25 млн. 30 мең сум салым кертүгә ирешкән «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Шәмәрдән магистраль газ үткәргечләре линия-җитештерү идарәсенә (җитәкчесе Нурисламов Р.Г.) беренче урын бирергә һәм коллективны беренче дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләргә.

Җитәкчегә акчалата бүләк тапшырырга һәм аеруча яхшы эшләүчеләрне бүләкләү өчен 10 мең сум күләмендә премия бүләргә.

2. Районның социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән, җирле бюджетка 2016 елда 13 млн. 755 мең сум салым кертүгә ирешкән «Саба» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (җитәкчесе Дәүлиев З.Д.) икенче урын бирергә һәм коллективны икенче дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләргә.

Җитәкчегә акчалата бүләк тапшырырга һәм аеруча яхшы эшләүчеләрне бүләкләү өчен 8 мең сум күләмендә премия бүләргә.

3. Районның социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән, җирле бюджетка 2016 елда 10 млн. 52 мең сум салым кертүгә ирешкән «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Сабагаз» эксплуатация-җитештерү идарәсенә (җитәкчесе Мөхетдинов И.И.) өченче урын бирергә һәм коллективны өченче дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләргә.

Җитәкчегә акчалата бүләк тапшырырга һәм аеруча яхшы эшләүчеләрне бүләкләү өчен 6 мең сум күләмендә премия бүләргә.

Р.Н. Минниханов